СИШӘМБЕ
9
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 32 (6754)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

БӨЕК ДАТАНЫ ЯҢА, ЗУР ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК!

Батыр Кызыл Армиябез үзенең героик һөҗүмен көннән-көн киң җәелдерә бара. Совет Информбюросы яңадан-яңа шәһәрләрнең, гаять әһәмиятле стратегик пунктларның алынуы турында һәркөн саен шатлыклы хәбәрләр китерә.

— Һөҗүм итеп баручы, изге совет җирләрен фашист кабахәтләрдән чистартучы фронтовикларыбызга булышлыкны тагын да күп тапкыр арттырыйк! Кызыл Армиянең тарихи 25 еллыгын яңа, зур җиңүләр белән каршылыйк!

Фронт өчен корал коючы тыл хезмәт ияләре әнә шул лозунг астында эшләп, үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар, бу йөкләмәләрне үтәү өчен һичбер нәрсәне дә кызганмыйча, героик Кызыл Армия һәм ватан таләп иткәннәрнең бөтенесен намус белән үтиләр.

Январь ае йомгаклары Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә киң колач алып җәелеп киткән социалистик ярышның гүзәл нәтиҗәләр биргәнлеген бик ачык күрсәтәләр. Баш инженеры иптәш Зафьянцев булган Н-че завод бу айда да ярышта җиңүче булып чыкты һәм Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын үзендә саклап калды. Партоешма секретаре урынбасары иптәш Ставер булган завод январь ае йомгаклары өчен шулай ук Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яулап алды. Баш инженеры иптәш Кадышев булган завод айлык планны 141,6 процентка үтәде. Җирле промышленность предприятиеләре барысы да диярлек үз планнарын арттырып үтәделәр. «Кызыл күнче» заводы айлык планны 104,3 процентка, «Светоч» фабрикасы—204,7 процентка, Чистайдагы «Труд» күн заводы—122,2 процентка, Казан промкомбинаты валовой продукция буенча—136,2 процентка, киң куллану товарлары буенча—163,4 процентка үтәделәр һ. б. 172 нче завод коллективы инициативасы белән башланып киткән, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган социалистик ярыш һәр урында да әнә шундый зур җиңүләргә китерә. Тыл хезмәт ияләре фронтка ярдәмне көннән-көн көчәйтәләр, Кызыл Армиягә, илгә кирәкле булган барлык төр продукцияне күбрәк һәм күбрәк җитештерәләр.

Ләкин ирешелгәннәр белән генә һич тә канәгатьләнеп калырга ярамый. Героик Кызыл Армия үзенең һөҗүмнәрен шулай өзлексез дәвам итсен һәм һаман көчәйтсен өчен, фашист кабахәтләрне изге совет җирләреннән бөтенләйгә куып җибәрсен һәм Гитлер армиясен тәмам тар-мар итсен өчен тылда тагын һәм тагын күбрәк көч куеп эшләргә кирәк. Безнең барлык халык хуҗалыгыбыз алдында 1943 нче елда гаять зур бурычлар тора. Фронт өчен, ил өчен продукцияне быел без тагын да күбрәк бирергә тиешбез. Сугыш шартларында лаеклы рәвештә эшләп, аз көч, аз материал, аз чимал белән без күп продукция җитештерергә тиешбез. Һәркайда һәм һәрнәрсәдә нык экономия—барлык эштә тимердәй закон булып әверелергә тиеш. «Чимал, ягулык, электр энергиясе, металл тотуда экономия һәм барлык төр җирле ресурсларны мобилизацияләү хәзер гаять зур әһәмияткә ия булып тора. Экономияле эшләү—ярышта катнашучыларның барысыннан да хәзер бигрәк тә әнә шул таләп итәлә» («Правда»).

Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә күп вакыт калмады. Бу тарихи дата хөрмәтенә алынган йөкләмәләрне үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәшне тагын да көчәйтү—бүгенге көндә барлык коллективлар алдында төп бурыч булып тора. Явыз дошманга каршы фронтта Кызыл Армия белән бергә, тылда героик хезмәт тә һөҗүм итә. Тылдагы стахановча хезмәт, кызылармеец коралы кебек үк, дошманга нык удар ул. Һәрбер эшче, инженер, техник, хезмәткәр үзенә тапшырылган участокта үзен фронтта, сугышның алгы линиясендә дип хис итсен, шундый ук куәтле энергия һәм омтылучанлык белән эшләсен.

Кызыл Армиянең 25 еллыгын фронтта да, тылда да яңа, зур җиңүләр белән каршылыйк!

Безнең гаскәрләр Фатеж, Краматорская, Азов шәһәрләрен, район үзәге һәм тимер юл станциясе Гостищевоны алдылар

1) 7 нче февральдә **Курскидан** төньяктарак безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә **Фатеж** шәһәрен алдылар һәм **Курск—Орел** шоссе юлын кистеләр.

2) Белгородтан төньяктарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге һәм тимер юл станциясе Гостищевоны алдылар һәм Белгород—Курск тимер юлын кистеләр.

3) **Украинада** безнең гаскәрләр **Краматорская** шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

4) **Ростов-Доннан** көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, **Азов шәһәрен** һәм тимер юл станциясен алдылар һәм, шулай итеп, Донның сулъяк ярында дошманның каршылык күрсәтүенең актык таянычын бетерделәр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КУРСК, КОРОЧА ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1) 8 нче февральдә генерал-майор иптәш **И. Д. Черняховский** гаскәрләре, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, Курск шәһәрен алдылар. Курскига беренче булып полковник иптәш **А. М. Бушин**, полковник иптәш **И. А. Гусев** һәм подполковник иптәш **С. Н. Перекальский** частьлары бәреп керделәр. Курск шәһәрен алуга, төньяк-көнбатыштан чолгап алу удары ясап, полковник иптәш **Д. Н. Голосов** һәм полковник иптәш **Т. К. Шкрылев** частьлары булышлык итте.

Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына.

2) **Белгородтан** төньяк-көнчыгыштарак безнең гаскәрләр каты сугыштан соң **Короча** шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СССР Верховный Советы Президиумы Указы

РСФСР составында Курган өлкәсе төзү турында

Курган өлкәсе төзү турында Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советы Президиумы керткән тәкъдимне расларга. Аның үзәге Курган шәһәрендә була.

Курган өлкәсе составына түбәндәгеләрне кертергә: Курган һәм Шадринск шәһәрләре, Альменевский, Белозерское, Варгаши, Галкино, Глядянское, Далматово, Звериноголовское, Каргополье, Китайское, Кирово, Курган, Куртамыш, Лебяжье, Лопатки, Макушино, Мехонский, Мишкино, Мокроусово, Мостовское, Ольховка, Петуховский, Половинное, Сафакуль, Уксянское, Усть-Уйское, Частоозерское, Чаши, Шадринск, Шатрово, Шумиха, Щучье, Юргамыш районнары (болар Челябе өлкәсе составыннан аерып алыналар), Армизонское, Бердюжье, Исетское, Упорово районнары һәм Ново-Заимка районының Верхний Манай, Видоново, Киселевское, Масальское, Нижний Манай, Пантелеево, Пятковское һәм Слабодчиково авыл советлары (болар Омск өлкәсе составыннан аерып алыналар).

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль, 6 февраль, 1943 ел.

ИПТӘШ СТАЛИНГА, КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ ҺӘМ СССР ХАЛЫКЛАРЫНА КОТЛАУЛАР

Чит илләрдәге оешмалардан—Австралиядән, Уругвайдан, Боливиядән, Кубадан иптәш Сталин исеменә түбәндәге телеграммалар алынды:

Австралия тимер юлчылары союзының Виктория штаты филиалы советы Кызыл Армиянең 2.000 миль озынлыктагы фронтта уңышлы һөҗүме һәм Ленинград блокадасын өзүе уңае белән чын күңелдән котлау җибәрә.

МЕЛЬБУРН. БРАУН, секретарь.

* * *

Кызыл Армиянең бөек җиңүләре бигрәк тә героик Сталинградның азат ителүе һәм Ленинград блокадасының өзелүе уңае белән СССР хөкүмәтенә һәм халкына безнең шатлыгыбызны белдерегез. Без җиңүгә ирешү өчен бөтен көчебезне җәеп җибәрергә тулысынча әзер торабыз.

ВЕЛЛИНГТОН, АВСТРАЛИЯ.

ЭТМОН, Россия белән элемтә җәмгыяте председателе.

* * *

СССР халкын һәм аның юлбашчысы Сталинны, гомуми азатлык юлында көрәшүче һәм нацистлар урдаларын юк итүче Кызыл Армияне котлыйбыз.

МОНТЕВИДЕО.

Көньяк Американың фашизмга каршы немецлар конгрессы.

ВКП(б) ның МОСКВА ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МОСКВА ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ ПЛЕНУМЫ

5—6 нчы февральдә ВКП(б) ның Москва өлкә һәм шәһәр комитетларының берләштерелгән пленумы булды. Пленум өч мәсьәләне тыңлады һәм тикшерде: «Москвауголь» комбинатының эше турында; хәрби хезмәткәрләрнең семьяларына ярдәм күрсәтү буенча совет органнарының һәм урыннардагы партия оешмаларының эшен яхшырту чаралары турында; өлкәдәге колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенә әзерлеге турында.

Пленумда ВКП(б) ның Москва Өлкә Комитетының һәм Москва шәһәр комитетының секретаре иптәш **А. С. Щербаков** чыгыш ясады.

Иптәш Щербаков «Москвауголь» комбинатының һәм аның җитәкчеләренең эшен тәнкыйть итте. Ул болай диде:

— Докладта һәм фикер алышуларда катнашкан кайберәүләрнең речьләрендә объектив сәбәпләрне сылтау итеп акланырга тырышу сизелде. Январь аенда эшнең канәгатьләнерлек булмавының төп сәбәбе исә комбинатның үзенең, кайбер трестларның һәм шахталарның начар эшләүләреннән гыйбарәт булды.

Күмер эшчеләренең артта калуының төп сәбәбе комбинатта эшнең тиешенчә оештырылмавыннан килеп чыккан. Кайбер трест һәм шахта җитәкчеләре әле эшне чын-чынлап оештырмыйлар. Кызыл Армиянең уңышлары уңае белән безнең эшчеләр зур энтузиазм күрсәтәләр, ләкин энтузиазм бары тик оештыру эшенә нигезләнгәндә генә производство уңышларына китерә ала.

Күмер промышленностеның кайбер работниклары вәгъдәләр бирергә яраталар, ә соңыннан аларны үтәмиләр. Вәгъдә биргәнсез икән—үтәгез! Большевикның сүзе нык булырга тиеш. Коры вәгъдәләр исә ныклы дәүләт дисциплинасы юклыкны күрсәтәләр.

Пленумда чыгыш сөйләүчеләр эшсез торулар турында, механизмнарның бозылуы турында, эш урынының әзерләнмәгәнлеге турында сөйләделәр. Бу да шулай ук тиешле оештыру эше юклыкны раслый.

Черек настроениеләрне һәм объектив сәбәпләргә сылтауны бетерергә кирәк.

Шахталарда хуҗалык һәм партия җитәкчелегенең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Партия оешмалары лавада, шахтада булган кимчелекләрне бетерү буенча, кешеләрне тәрбияләү буенча көн саен тырыш эш алып барырга тиешләр.

Москва күмер бассейнына инде күп нәрсәләр бирелде. Бу ярдәм көннән-көн артачак. Ләкин хәзер илебез һәм партия москвалылардан, Москва бассейны работникларыннан күмерне кирәк булган кадәр бирүне таләп итәргә хаклылар. Без Кызыл Армиянең уңышларына резолюцияләр һәм декларацияләр белән түгел, бәлки күмер белән җавап бирергә тиешбез.

(ТАСС).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

7 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның зур көчләренең каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар һәм Батайск шәһәренә килә торган якындагы юлларга барып чыктылар. Совет танкистлары һәм мотопехотасы, артиллерия һәм авиация ярдәме белән, Койсугны алдылар һәм төнлә белән Батайскига барып керделәр. Каты сугышлар нәтиҗәсендә безнең сугышчылар, урамнарны һәм йортларны гитлерчылардан бер-бер артлы чистартып, кичә Батайск шәһәрен һәм тимер юл узелын тулысынча алып бетерделәр. Дошман авыр югалтуларга дучар ителде. Безнең частьлар бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Купянскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм операцияләрен дәвам иттерделәр. Бер участокта дошман ашыгыч рәвештә резервлар китерде һәм берничә тапкыр контратака ясады. Н-че берләшмә гвардеецлары гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар. 500 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 6 танкысы сафтан чыгарылды. 80 немец солдаты плен алынды. Безнең сугышчылар, дошманны куып барып, халык яши торган ике зур пунктны алдылар.

* * *

Курскидан көнчыгыштарак безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң халык яши торган берничә пунктны гитлерчылардан чистарттылар. Бер терәк пункты районында 6 орудие, 2 миномет, бик күп автоматлар һәм пулеметлар кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

Һава сугышларында совет очучылары немецларның 8 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Шушы көннәрдә Украина партизаннарының бер отряды халык яши торган бер зур пункттагы немецлар гарнизонына кинәт һөҗүм ясаган. Бик каты сугышта партизаннар 200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаганнар. Январь ахырында бу отрядның партизаннары немецларның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Бер паровоз, автомашиналар төялгән 8 платформа һәм майлау материаллары төялгән 3 платформа җимерелгән.

* * *

Рождество көннәрендә Гитлерның Украинадагы наместнигы, Украина халкының палачы немец Эрих Кох совет-немец фронтында сугышучы Көнчыгыш Пруссия солдатларына хат җибәргән. Күптән түгел бу хат кулга төшерелгән документлар арасында табылды. Гитлерчы сатрап немец солдатларына сугыш беткәннән соң һәртөрле байлыклар һәм алтын таулар вәгъдә итә. Ул аларга сугыш ганимәтләре төсендә Украинаның уңдырышлы җирләрен һәм байлыкларын вәгъдә итә. Кох болай дип яза: «Фюрерның кушуы буенча мин идарә итә торган Украинаның гаять киң җирләрендә барлык солдатлар өчен мәйдан бар. Монда теләгән кешеләрнең һәрберсе өчен урын бар. Сез бу илнең исәпсез күп байлыкларын беләсез. Сез миңа ышаныгыз, мин сезне һәм сезнең туганнарыгызны тәэмин итү өчен Украинаның актык байлыгын сыгып алырмын».

Украинаның байлыклары турында Эрих Кох юкка гына тынычсызлана. Аның планнары беркайчан да эшкә ашмас. Чыннан да, безнең җиребездә һәрбер немец-фашист басып алучы өчен икешәр-өчәр аршын җир табылыр. Сталинград тирәләрендә генә дә инде бу норманы йөз меңнәрчә үтерелгән гитлерчылар алдылар. Советлар Украинасының азатлыгына, намусына һәм бәйсезлегенә кул сузган немец-фашист оккупантлар һәм аларның бандитлар атаманы Эрих Кох шул ук норманы алырлар, ләкин шуннан һич тә артык булмас.

* * *

Кызыл Армиянең бер группа сугышчылары һәм командирлары Воронеж өлкәсенең Русская Тростянка авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турында акт төзеделәр. Актта болай диелә: «Немец басып алучылар колхозның 3 дуңгыз асраучылык фермасын талаганнар һәм юк иткәннәр. Колхозчыларның 32 сыерын, 100 бозавын, 500 сарыгын һәм барлык ашлыкларын талап алганнар. Бандитлар крестьяннарны ерткыч төстә мыскыллаганнар һәм көчләгәннәр. Немецлар 65 яшьлек Куксовны камчылар белән кыйнаганнар, колхозчы Дарья Л. ны көчләгәннәр, Петр Бражниковны, Филипп Ампиловны, Ксения Лохинаны, Петр Уваровны, Антон Часовниковны, Феодосия Часовниковны һәм Русская Тростянка авылының башка кешеләрен үтергәннәр».

* * *

Старый Осколдан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть подразделениеләре көчле итеп ныгытылган, халкы яши торган ике пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде, 6 танкысы һәм 2 бронемашинасы яндырылды һәм зарарланды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар һәм Орел—Курск шоссе юлын кистеләр. Бер участокта немецлар. совет частьларының алга баруларын тоткарларга маташып, контратака ясап карадылар. Безнең сугышчылар, фланглардан удар ясап, гитлерчыларны тар-мар иттеләр. 300 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде һәм 280 кеше плен алынды. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары 2 орудие, төрле сугыш йөкләре төялгән 42 автомашина һәм сугыш припаслары төялгән бер обоз кулга төшерделәр.

* * *

Ленинград өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды Н. шәһәрендә немецларның учреждениеләренә кыю һөҗүм ясаган. Бер группа партизаннар часовойларны үтергәннәр һәм шәһәр комендатурасы бинасын шартлатканнар. Йортта булган гитлерчылар, шул исәптән өлкән штаб офицерлары, барысы да үтерелгән.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтның бер участогында немецларның 304 нче пехота дивизиясеннән бер группа солдатлар плен бирелделәр. Пленныйлардан Карл Сима, Эрнс Шмидт, Рудольф Фрауендорф һәм башкалар болай диделәр: «Декабрьда Бельгия—Голландия—Дрезден—Краков — Днепропетровск—Ростов—Лихая маршруты буенча безнең дивизия Франциядән чыгып китте. Юлда офицерлар безгә Сталинградның немец гаскәрләре тарафыннан чолганып алынганлыгын һәм бу шәһәрнең алынуы көннән-көн кетеп торылганлыкны сөйләделәр. Лихаяда без Сталинградта рус гаскәрләре түгел, бәлки немец гаскәрләре чолганып алынганлыкны белдек. Солдатларның настроениесе кинәт төшеп китте. Көнчыгыш фронттагы беренче сугышларда ук безнең дивизия чолганып алынды һәм бик авыр югалтуларга дучар ителде. 573 һәм 574 нче полклар тар-мар ителделәр. Һәркем үзен куркыныч астына куеп һәм тәвәккәлеккә бирелеп чолганыштан үзе чыгарга тырышты. Чигенгән чакта командование яралыларны язмыш кочагына ташлап калдырды һәм алар өшеп үлделәр. Исән калган солдатлар яңадан чолганышка эләгербез дип куркалар һәм бик борчылалар».

* * *

Түбәндә Курск өлкәсенең Солоти авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец оккупантлар колхозчыларны бөлдерделәр, колхоз милекләрен таладылар һәм яндырдылар. Гитлерчылар колхозчыларның 80 баш терлеген талап алдылар, колхоз каралтыларын һәм 13 торак йортны яндырдылар. Алар авыл халкын иксез-чиксез мыскылладылар, кыйнадылар, газапладылар. Фашист палачлар 70 яшьлек Г. Шеховцовны, колхозчылардан Евдокия Бабенконы, Анна Бабенконы һәм тагын 7 гражданны үтерделәр». Актка авыл кешеләреннән Н. Духин, О. Устинникова, И. Шеховцов, А. Сергеева һәм А. Винокурова кул куйды.

7 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче февральдә Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, **Фатеж** шәһәрен алдылар һәм Курск—Орел шоссе юлын кистеләр.

Белгородтан төньяктарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Гостищевоны** алдылар һәм Белгород—Курск тимер юлын кистеләр.

Украинада безнең гаскәрләр **Краматорская** шәһәрен һәм тимер юл узелын, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Савинцыны**, район үзәге **Петровскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Чепельны**, **Протопоповканы**, **Червоный Шахтерны** һәм **Грушеваханы** алдылар.

Ростов-Доннан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, **Азов** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук халык яши торган зур пунктлардан **Кагальникны** алдылар. Ростов-Доннан көньяк-көнчыгыштарак безнең частьлар халык яши торган зур пунктлардан Ольгинскаяны алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

31 нче январьдан 6 нчы февральгә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 149 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 93 самолет югалттык.

* * *

6 нчы февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар. 9 артиллерия батареясының утын бастырдылар. 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер ротага якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар. Н-че берләшмә дошман оборонасының көчле итеп ныгытылган күп кенә узелларын алды. Безнең сугышчылар немецларның моторлаштырылган бер отрядын юк иттеләр һәм 10 автомашина, танкка каршы ата торган 4 орудие кулга төшерделәр. Икенче бер участокта совет танкистлары су чиге аркылы үтеп чыктылар һәм халык яши торган 3 пунктны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды

* * *

Барвенково районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Совет частьлары, дошманның берничә контратакасын кире кайтарып, алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Халык яши торган бер пункт районында гына да 12 орудие, шулардан авыр калибрлы 4 орудие, 31 пулемет, 9 миномет, 2 сугыш припаслары склады һәм 3 азык склады кулга төшерелде. Н-че часть танкистлары немецларның 6 танкысын, 3 самоход орудиесен һәм бер батальонга якын пехотасын юк иттеләр.

* * *

Купянскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Совет танклары һәм мотопехотасы, кинәт һөҗүм ясап халык яши торган әһәмиятле бер пунктны алдылар. Дошман гарнизоны бөтенләй кырып бетерелде. Күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Н-че часть сугышчылары бик каты сугышта 400 гә якын гитлерчыны кырдылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 2 танк, 7 орудие, 19 пулемет, бер ашлык склады, 2 әйбер склады һәм бер радиостанция кулга төшерелде.

8 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

8 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көньяктарак немецлар үзләренең моннан әлек югалткан позицияләрен кайтарып алырга маташып карадылар. Безнең гаскәрләр дошманны көчле миномет һәм пулемет уты белән каршыладылар. Дошман алып ташланды. Сугыш кырында дошман солдатларының һәм офицерларының күп үле гәүдәләре калды.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Гвардияче танкистлар халык яши торган бер зур пункт өчен булган каты сугышларда немецларның 11 танкысын яндырдылар һәм зарарладылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта бер группа совет танклары, дошман тылына үтеп, немецларның бер пехота колоннасын тар-мар иттеләр.

* * *

Купянскидан көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары дошманга каршы сугышта 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар, дошманның 4 танкысын һәм 3 орудиесен юк иттеләр. 45 автомашина, бер сугыш припаслары складлары, күп кораллар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр төнлә белән халык яши торган бер зур пунктка бәреп керделәр, урам сугышларында немецларның бер ротага якын пехотасын юк иттеләр һәм бу пунктны алдылар. 2 танк, танкка каршы ата торган 3 орудие һәм 16 пулемет кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны азат иттеләр. 400 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 22 танк, 33 орудие, 42 пулемет, 30 миномет, 20 автомашина, 4 радиостанция, 10.000 снаряд, бик күп патроннар һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Курск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды дошман гарнизоннарына берничә һөҗүм ясаган һәм 130 гитлерчыны кырып ташлаган. Бу отрядның партизаннары моннан бер атна элек немецларның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 2 паровоз, 4 платформа, 12 вагон җимерелгән. Икенче бер отрядның партизаннары берничә урыннан тимер юлны шартлатканнар һәм 5 километр озынлыкта телефон-телеграф чыбыкларын кисеп алганнар.

* * *

Итальяннарның «Равенна» дивизиясенең 37 нче полкының плен алынган командиры полковник Джованни Колдини болай диде: «Минем подразделениеләр оборонада торалар иде һәм алар көчле ныгытмаларга урнашканнар иде. Русларның танклары, һөҗүм башлап, безнең оборонаны өзделәр һәм изеп киттеләр. Без гадәттән тыш авыр хәлдә калдык. Полкның уң флангысында немецларның 298 нче дивизиясе частьлары тора иде. Минем теткәләнгән полкыма немецлар бернинди дә ярдәм күрсәтмәделәр. Шуннан соң мин чигенергә карар бирдем, ләкин руслар барлык чигенү юлларын кистеләр һәм полкның калдыклары, штаб белән берлектә, пленга эләктеләр». Соңыннан полковник Колдини болай диде: «Немецлар электр белән эшли торган яңа пулемет турында күп яздылар. Ләкин андый пулемет дөньяда юк. Ул бөтенләй уйдырма гына. Дөньяда булмаган «электрик пулемет» турында күтәрелгән бөтен шау-шуны пропаганда максаты белән уйлап чыгардылар».

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсе, Репьевка авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Безнең авылда гитлерчылар канлы суеш оештырдылар. Фашист палачлар колхозчы Воронковны астылар, колхозчылардан Тихон Волвенкинны, Петр Токарскийны, Ольга Пакаринаны һәм башка күп кешеләрне үтерделәр. Фашист җан кыючылар граждannардан барлыгы 220 кешене үтерделәр һәм үтергәнче газапладылар. Немец солдатлары һәм офицерлары авыл советына караган 7 колхозны таладылар һәм бөлдерделәр, 1.500 баш терлекне куып алып киттеләр һәм колхозның бик күп милекләрен талап алдылар. Кызыл Армиянең удалары астында чигенгән чакта немецлар ике мәктәпне, көтепханәне, кино-театрны, больницаны һәм бала тудыру йортын яндырдылар». Актка авыл советы председателе Е. Нефедченко, Репьевка авылы гражданнарыннан К. Фабрицкая, Е. Тереничченко. Ф. Щербаковалар кул куйды.

Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа җиңүләр белән каршылыйк!



Вахитов исемендәге жиркомбинатның баш инженеры иптәш Н. Г. Щербаков уйлап табу чаралары һәм гади рационализацияләр үткәрү юлы белән материалларга һәм электр энергиясенә бик күп экономия ясау мөмкинлеген тапты. Күптән түгел иптәш Щербаковны хөкүмәтебез Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде. Рәсемдә: иптәш Щербаков үзенең эш кабинетында.

Б. Невзоров фотосы.

ФРОНТТАГЫЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫП

Туган илебез фронтларда немец оккупантларына каршы көчле һөҗүмне көчәйткәннән-көчәйтә бара. Кызыл Армия көннән-көн зуррак җиңүләргә ирешә. Шушы уңышлар белән рухланып, Тәкәнеш районы колхозлары язгы чәчүгә әзерлекне соңгы көннәрдә аеруча яхшырттылар.

Тукай исемендәге колхозда язгы эшләргә әзерлек барлык тармаклар буенча да кызу темплар белән бара. Ремонт планлы рәвештә нык график белән үткәрелә. 11 сабан, 12 тырма, 2 культиватор һәм 2 чәчү машинасы төзек инде. Агротехника чаралары үткәрү буенча да һәрбер бригаданың планы бар. Басуга 173 тонна тирес чыгарылды. Ашлама өчен 5 центнер көл, 20 центнер кош тизәге, 34 центнер фекали җыелды. 30 кеше агротехника түгәрәгендә авыл хуҗалыгы эшләренә өйрәнәләр. Түгәрәкнең 6 тапкыр занятиесе булды инде.

«Удар ел» колхозы да быел язгы чәчүгә әзерлектә үзенең исеменә лаеклы эшли. Быелгы язны—җиңү язын яхшы әзерлек белән каршыларга тырыша. Бу колхоз басуга 674 тонна тирес чыгарды. Бик күп ашламалар җыйды. 250 гектар мәйданда кар тотты. Хәзер, Кызыл Армиянең 25 еллыгына кадәр авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауны тәгәлләү өчен ныклы чаралар күрелә.

Ф. ХӘМЗИН.

ЯРЫШ АЛДЫНГЫЛАРЫ

ВЦСПС һәм Авиация промышленносте халык комиссариаты 1943 нче елның январь аендагы социалистик ярыш йомгакларын карап чыктылар һәм карар бирделәр:

Директорлары Белянский, Марочкин, Абрамов, Дикарев, Федин иптәшләр булган заводларда Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын саклап калырга.

Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын директоры иптәш Жезлов булган заводтан алып, директоры иптәш Лукин булган заводка тапшырырга; директоры иптәш Баландин булган заводтан алып, директоры иптәш Морозов булган заводка тапшырырга; директоры иптәш Окулов булган заводтан алып, директоры иптәш Березин булган заводка тапшырырга.

АЙЛЫК ПЛАН АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярышка кушылып алган йөкләмәләрне Фармзавод коллективы намус белән үтәп килә. Январь аеның производство программасы 103 процентка үтәлде. Бу айда заводта 1.000 киловатт-сәгать электр энергиясенә, 2 тонна ягулыкка экономия ясалды. Чимал тотуның коэфициенты 0,2 процентка киметелде.

Химия цехы һәм фасовочный цех ярышта алдынгы булып баралар. Химия цехы аппаратчигы иптәш Лазарева, эшне яхшы оештыруы, планнарны арттырып үтәүгә ирешүе өчен, «Сәламәтлек саклау отличнигы» значогы белән бүләкләнде. Цехның Кузнецова, Куражева кебек күп кенә стахановчылары сыйфат өчен көрәштә зур уңышларга ирештеләр. Алар нормаларын системалы рәвештә арттырып үтәү белән бергә, һичбер брак эшләмиләр, бары тик югары сыйфатлы продукция генә бирәләр.

Заводның фасовочный цехы (начальнигы иптәш Сандина) айлык планны 23 нче январьга ук тәгәлләде. Цехта яңадан-яңа ярыш алдынгылары үсеп чыгалар. Новикова, Сабирова, Таһирова һ. б. иптәшләр нормаларны һәрвакыт бик күп арттырып үтиләр. Иптәш Хөснетдинова цехта әле өйрәнчек булып кына эшли. Ләкин үз эшен бик яратуы, ярышта алдынгылык өчен, фронтка һәм илгә медицина әйберләрен тагын да күбрәк бирү өчен көрәшүе нәтиҗәсендә ул көн саен 2—2,5 норма бирүгә ирешә.

Завод коллективы февраль ае планын героик Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә—23 нче февральгә тәгәлләү өчен көрәшә.

СТАХАНОВЧЫЛАР КОПИЛКАСЫ

Н-че заводның начальнигы иптәш Дождев булган бүлеге Кызыл Армия көненә планнан тыш 20 изделие эшләп чыгарырга йөкләмә алган иде. Кызыл Армиянең уңышлы һөҗүмнәре белән рухланган коллектив январь аенда зур күтәренкелек белән эшләде. Бүлектәге эшчеләрнең һәрберсе һәркөнне планнан тыш берничә деталь бирү өчен көрәште. Бу детальләр мастер иптәш Бурлуцкий инициативасы белән оештырылган стахановчы копилкага салына бардылар.

Коллективның барлык көчләр белән Кызыл Армиягә ярдәм итәргә теләве, бердәм рәвештә дусларча эшләве гүзәл нәтиҗәләр бирде. Бүлек январь ае планын срогыннан элек үтәде. Планнан тыш Кызыл Армия көненә бүләккә 20 изделие эшләп тапшырды. Йөкләмә 23 көнгә элек үтәлде.

Стахановчылар бу детальләрне эштән соңгы вакытларда эшләделәр. Планнан тыш эшләнгән детальләр өчен тиешле хезмәт хакын «Марина Раскова» исемле авиаэскадрилья төзелеше фондына кертәләр.

Бүлек коллективы Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказына җавап итеп, февраль ае программасын 23 нче февральгә—Кызыл Армиянең еллыгы көненә тәгәлләргә сүз бирде.

Ремонтның темпын көчәйтергә

БАЛТАЧ. (Телефон буенча). Районның алдынгы колхозлары язгы чәчү вакытында кирәкле авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтны күптән тәгәлләделәр инде. Мәсәлән, «Кызыл көч» колхозы тырмалар, культиваторлар һәм чәчкечләрне тулысынча төзек хәлгә китерде.

Ләкин районның күп кенә колхозларында авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт эшләре бөтенләй башланмаган. Райондагы 1.460 сабанның 703 е, 1.220 тырманың 588 е, 360 культиваторның 155 генә төзек. Ремонтланган бер генә машинаның да сыйфаты комиссия тарафыннан тикшерелеп кабул ителмәгән.

Язгы эшләргә әзерлекнең начар торуын район җир бүлеге мөдире иптәш Зәйнуллин колхоз председательләренең еш алмашынып торуы белән, тимерчеләрнең җитешмәү, күмер һәм башка әйберләрнең азлыгы белән аңлатмакчы була. Билгеле, бу сәбәпләр ремонтны тизрәк тәгәлләүгә комачаулыйлар. Ләкин бу сәбәпләр район җир бүлеге работникларының үзләренең эшлексезлекләре аркасында килеп чыкканнар. Мәсәлән, «Кызыл яшьләр» колхозында председатель 5 тапкыр алмашынган. Председательләрнең еш алмашынып торуы сәбәпле бу колхозда язгы чәчүгә әзерлек гафу ителмәслек дәрәҗәдә акрын бара. «Большевик» колхозында да күмер һәм запас частьлар булмаганлыктан ремонт эшләре тукталып тора. Мондый фактлар башка колхозларда да күп.

Районда күмер яндыру өчен мөмкинлекләр бар. Үзган ел район урман хуҗалыгы (директоры иптәш Бәдретдинов) колхозларны әзер күмер белән тәэмин итеп торды. Урманның участогында күмер яндырырга мөмкин. Ләкин быел бу эш оештырылмаган. Колхозлар 60 километр ераклыктагы Марий республикасыннан күмер алып кайтырга мәҗбүр булалар.

Колхоз тимерчеләреннән файдалану да яхшы оештырылмаган. Тимерчелекләрдә эш иртән 8 сәгатьтә генә башлана һәм кич 3 сәгатьтә үк туктала. Күмер булмау һәм башка сәбәпләр аркасында күп вакытта тимерчеләрнең вакыты бушка үтә.

Районда барлыгы 35 тимерче бар. Бу, колхозларның 87,5 проценты тимерчеләр белән тәэмин ителгән дигән сүз. Шулай булгач, аларга тулы эш шартлары тудырганда районда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтны бик тиз вакыт эчендә тәгәлләргә мөмкин. Тимерче юк, күмер җитми, дип сылтарга урын юк.

Ф. МӘҢГӘРЛЕ.

Төшерелгән, кушылган һәм... онытылган

— Иптәш Әхметов, колхозларда бәрәңге кисентесе күпме әзерләнде инде?.

— Җыябыз

— Ничә центнер җыелды соң?

— Без бу турыда колхозларга кәгазь төшердек. Менә копиясе, укып карагыз.

Район җир бүлеге мөдире Әхметов һәм район советы башкарма комитеты председателе Михайлов иптәшләр кул куйган бу кәгазьдә түбәндәгеләр язылган: «Татарстан Совнаркомының 1942 нче ел карары һәм район советы башкарма комитетының утырышы карары нигезендә район җир бүлеге бәрәңге кисентесе әзерләү буенча сезгә план җибәрә. Бу планны алу белән һәрбер колхозчыга һәм хезмәткәрләргә заданиене җиткереп, үтәлешне тәэмин итәргә кушыла».

Шул ук кәгазьдә кисенте җыелу турында һәр биш көн саен район җир бүлегенә мәгълүмат биреп торырга кушыла.

Төшерелгән, кушылган һәм.. онытылган.

Хәзергә кадәр районда 900 центнер урынына бары 22 центнер тына кисенте әзерләнүе әнә шулай кәгазь төшерү белән тынычлану нәтиҗәсе булып тора. Тукай, Вахитов һәм Тельман исемендәге колхозлар кисенте җыю эшенә бөтенләй керешмәгәннәр дә әле. Эш башланган күп кенә колхозларда кисентеләрне саклауга бөтенләй әһәмият бирелми.

Бәрәңге кисентесе җыю буенча Наркомзем тарафыннан бирелгән план үтәлсә, бу районда бәрәңге чәчү мәйданын кимендә 180 гектарга киңәйтергә мөмкин булачак. Кызыл юл районы оешмалары, бигрәк тә район җир бүлеге, бу әһәмиятле чарага игътибарсыз карашны бетерергә тиешләр.

Ф. ГАЛИЕВА.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

8 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

8 нче февральдә безнең гаскәрләр, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә, Курск шәһәрен алдылар.

Белгородтан төньяк - көнчыгыштарак безнең гаскәрләр каты сугыштан соң Короча шәһәрен һәм халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар.

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре район үзәге һәм тимер юл станциясе Старо-Щербиновсаяны, район үзәкләре Александровканы, Ейское - Укреплениене, Камышеватскаяны, халык яши торган зур пунктлардан Новокорсунскаяны, Дядьковскаяны, Шабельскаяны, Глафировканы, Николаевканы, Должанканы, тимер юл станцияләре Платинировскаяны һәм Пластуновскаяны алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр әлекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

7 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 4 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер батальонга якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Дон районында безнең гаскәрләр, дошманның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Ростов-Дон шәһәреннән көнчыгыштарак алдагы пехота подразделениеләре зур бер станицата бәреп керделәр һәм аны гитлерчылардан чистарталар. Икенче бер участокта Н-че кавалерия часте, кинәт һөҗүм ясап, дошман оборонасының көчле итеп ныгытылган бер пунктын алды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Краматорская районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Моторлаштырылган Н-че часть 300 дән артык гитлерчыны юк итте һәм халык яши торган берничә пунктны алды. 7 орудие, 19 пулемет, бер радиостанция һәм сугыш милекләре төялгән 32 автомашина кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең артиллеристлар һәм бронебойщиклар немецларның 7 танкысын юк иттеләр һәм бер батальон дошман пехотасын таркаттылар.

* * *

Изюмнан көнбатыштарак дошман оборонаның бер чигендә совет частьларының һөҗүмен тоткарларга маташты. Безнең кәрәкәттәге отрядларыбыз дошманның тылларына барып керделәр һәм аның оборонасын какшаттылар. Гитлерчылар ашыгыч рәвештә чигенделәр. Безнең сугышчылар 11 орудие, 2 танк, танкка каршы ата торган 18 мылтык, 34 пулемет, 3 сугыш припаслары складын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер көн эчендә 1.000 нән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды. 2 танк, 5 орудие, 26 автомашина, 12 мотоцикл, бер сугыш припаслары һәм азык склады, шулай ук башка күп сугыш милекләре кулга төшерелде. Чигенгән чакта немецлар үзләренең яралыларын язмыш иркенә ташлап кына түгел, бәлки аларны юк итеп тә киткәләр. Тимирязово авылында гитлерчылар 27 яралы немец солдатлары һәм офицерлары яткан госпитальне шартлатканнар.

* * *

Украинада хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары немецлар кулындагы бер тимер юл станциясенә кинәт һөҗүм ясаганнар. Совет патриотлары 3 паровозны һәм сугыш йөкләре төялгән 11 платформаны юк иткәннәр. Бу отрядның бер группа партизаннары, пехота коралларыннан атып, немецларның бер самолетын бәреп төшергәннәр. Икенче бер отрядның партизаннары берничә сәгать буена зур бер авылда немецлар гарнизонына каршы бик каты сугыш алып барганнар. 100 дән артык гитлерчы кырылган, бер сугыш припаслары склады һәм 7 немец офицеры урнашкан бер йорт шартлатылган. 5 пулемет, 61 винтовка, бер миномет һәм берничә ящик мина кулга төшерелгән.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсе, Татарино авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец бандитлар килгәнчегә кадәр Татарино авылы колхозчылары таза һәм культуралы тормышта яшиләр иде. Гитлерчылар халыкны, бер нәрсәсен дә калдырмыйча, талап бетерделәр, мәктәпне, клубны, бала тудыру йортын, медицина пунктын, колхозның җәмәгать каралтыларын һәм күп колхозчыларның йортларын җимерделәр һәм яндырдылар. Шулай ук немецлар чиркәүне дә яндырдылар. Фашист палачлар авыл халкыннан Анастасия Сапрыкинаны, 4 бала анасы булган Марфа Шапринаны һәм Ксения Сапрыкинаны атып үтерделәр». Актка капитан Г. Виницкий, майор В. Алпасийский һәм авыл кешеләреннән И. Сапрыкина, А. Чернышев, А. Чунин, А. Коренков һәм И. Гончаренколар кул куйды.

СТАЛИНГРАД ӨЧЕН СУГЫШ — ДӨНЬЯДА БУЛГАН СУГЫШЛАРНЫҢ ИҢ ЗУРСЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ СТАЛИНГРАД ЯНЫНДАГЫ ҖИҢҮЕ ТУРЫНДА АМЕРИКА МАТБУГАТЫ

НЬЮ-ЙОРК, 6 февраль. (ТАСС). «Нью-Йорк Уорлд телеграм» газетасы, совет гаскәрләренең Сталинград янындагы җиңүләре союздаш илләрдә гаять зур күтәрелеш тудырды, ди һәм бу җиңүне союздаш илләренең сугышның барышында борылыш пункты башлануның күрсәткече дип карауларын әйтә. Газета Кызыл Армиянең хәрби сыйфатлары, аның командирларының осталыгы югары дәрәҗәдә икәнлекне, фронт линиясе артында гражданнар халкының гаять нык торганлыгын күрсәтеп үтә. Һәм, шушы сыйфатлар аркасында Кызыл Армия Германия армиясенең җиңелмәслеге турындагы әкиятне җимерде, ди.

Нью-Йоркта чыга торган «Сэн» газетасының фикеренчә, Германия гаскәрләренең Сталинград янында тар-мар ителүләре һәм юк ителүләре нәтиҗәсендә Гитлерның үзенең дәрәҗәсенә авыр удар ясалган. Германия халкы Гитлерның Германия армияләре өстенә китергән һәлакәт өчен җаваплы дип саный һәм Германия пропагандасы әвәләп чыгара торган һәртөрле аклануларга ышанмый.

Вашингтонда чыга торган «Стар» газетасы болай дип яза: «Сталинград өчен булган сугыш—тарихта иң зур сугышларның берсе. Ул русларның тулы җиңүе белән һәм күчәр державалары гаскәрләре өчен авыр һәлакәт белән тәмам булды. Сталинград сугышында руслар кешенең ихтыярын җиккән тәкъдирдә гаять зур киртәләрне җиңәргә мөмкин икәнлекне күрсәттеләр. Сталинград немецлар өчен үткән бөтен дөнья сугышында булган Верденга караганда күп дәрәҗәдә куркынычлырак булып чыкты».

Газеталар Германия армиясенең Сталинград янында һәм Совет-Германия фронтының башка участокларында колак ишетмәгән югалтуларга дучар булганлыгын аеруча күрсәтеп үтәләр. «Чикаго дейли ньюс» газетасы болай дип яза: «Нәтиҗәдә немецлар, бигрәк тә Сталинград янындагы югалтуларны каплау өчен Көнбатыш Европадан СССР га каршы фронтка тагын 22 дивизия җибәрергә мәҗбүр булдылар».

Радио коментатор Харгрейс болай ди: «Сталинград өчен булган сугыш әлегә кадәр булган сугышлар тарихында иң зур сугышлар белән бер урында торыр. Бу сугышта Сталинның иң бөек хәрби стратег икәнлеге ачык күренде».

ГИТЛЕРЧЫЛАР ЛАГЕРЕНДА ТЫНЫЧСЫЗЛЫК

ЖЕНЕВА, 7 февраль. (ТАСС). Соңгы вакытларда гитлерчылар матбугаты Совет—Германия фронтындагы вакыйгалар уңае белән ачыктан-ачык борчылу күрсәтә. «Лицманштеттер цейтунг» газетасы болай дип яза: «Көнчыгыш фронттан куркынычлы хәбәрләр килә. Большевиклар, каяндыр табып, сугышка гаять күп техника җибәреп, безнең позицияләргә ярсуланып штурм ясыйлар. Бу дәһшәтле сәгатьтә фронт немецлардан чиктән тыш көч куюны таләп итә».

Гитлерчы газеталар, берничә тапкырлар инде, советларның резервлары бөтенләй бетте дип, ә Кызыл Армиянең көчләре һәм техникасы юк ителде дип игълан иткәннәр иде. Хәзер инде алар, элек нәрсә язганнарын онытып, Кызыл Армиянең кешеләре һәм техникасы өстен булу турында акыралар.

Гитлерчы газеталар, немецларны Германиядә игълан ителгән «тотальная мобилизация» гә булышлык итәргә чакыралар, ләкин Германиядә бу «тотальная мобилизация»гә каршылык күрсәтүнең бик көчле икәнлеген һәм көннән-көн көчәя баруын яшереп кала алмыйлар. «Данцигер форпостен» газетасы «хәзерге вакытта хәл артык җитди һәм көрәш артык каты һәм рәхимсез» икәнлекне аңларга теләмәүче немецларга каршы янаулар белән ташлана. Газета, «тиешеннән артык игътибарсызлык күренә, дип зарлана. Газета болай ди: «Хәзер һәртөрле «ләкин» нәр, «әгәр дә» ләр заманы түгел, вак-төяк куркулар һәм сугышның көндәлек таләпләрен игътибарсыз калдыру заманы түгел». Шуңа иярел «Дейче альгемейне цейтунг» газетасы: «Беркем дә хыянәтчегә әверелмәскә тиеш»,—дип яза.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 6 февраль. (ТАСС). Төньяк Африкадагы союзниклар штабы дошманның контратакалары нәтиҗәсендә союзниклар гаскәрләренең Җәбәлемансурдан кысрыклап чыгарганлыкларын хәбәр итә. Һава начар булганлыктан авиациянең активлыгы чикле булган.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА ХӘРБИ КОМИТЕТ ТӨЗЕЛҮ

ЛОНДОН, 6 февраль. (ТАСС). Төньяк Африкадагы союзниклар штабының хәбәр итүенчә, генерал де Голль Франция биләмәләре советын бетергән һәм аның урынына хәрби комитет төзегән.

ЧЕРЧИЛЛЬНЕҢ АНГЛИЯГӘ КАЙТУЫ

ЛОНДОН, 7 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Черчилльнең Англиягә кайтканлыгын хәбәр итә.

Франция милли комитеты составында үзгәрешләр

ЛОНДОН, 6 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция республикасы чит ил эшләре министрлыгының элекке политик бүлек директоры, Франциядән качкан һәм моннан берничә көн элек де Голльга кушылган Рене Массильи, Плевен урынына, Франция милли комитетының чит ил эшләре буенча милли комиссары итеп билгеләнгән.

Плевен үз урынына Массильины билгеләргә генерал де Голльга үзе тәкъдим иткән. Плевен колонияләр эшләре буенча милли комиссар булып кала.

Алжирда интернировать ителгән коммунист депутатларны азат итү

ЛОНДОН, 6 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Алжирдан алып хәбәр итә:— Төньяк Африкада генерал Жиро приказы буенча Франция парламентының 7 коммунист депутаты тоткыннан азат ителгән. Алар Францияне Германия басып алгач ук Виши хөкүмәте тарафыннан кулга алынып, Төньяк Африкага җибәрелгәннәр һәм шунда төрмәгә ябылганнар иде.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

«КАЗАН ТИМЕР ЮЛЧЫСЫ» ИСЕМЛЕ ТАНКЛАР КОЛОННАСЫ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ

Казан тимер юлы работниклары, Кызыл Армиянең уңышлары белән рухланган хәлдә, «Казан тимер юлчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 4 миллион сум акча керттеләр һәм 1 миллион сумлык дәүләт заемнары облигацияләрен тапшырдылар.

Черусти узелының тимер юлчылары миллион ярым сум җыйдылар. Казан юл дистанциясе коллективы 140 мең сум кертте.

Сарапул дистанциясенең ремонт эшчесе Е. Мокшанов 2.286 сум, җыештыручы А. Казакова 1.000 сум бирделәр.

МОНГОЛИЯ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕНЕҢ КИТҮЕ

Монголия халкыннан фронттагы Кызыл Армия сугышчыларына һәм командирларына бүләкләр китергән Монголия Халык Республикасы делегациясе 6 нчы февральдә Москвадан Улан-Баторга китте.

Вокзалда делегацияне Чит Ил Эшләре Халык Комиссары урынбасары В. Г. Деканозов, Эчке Эшләр Халык Комиссары урынбасары В. Н. Меркулов, Тышкы Сәүдә Халык Комиссары урынбасары Ю. М. Каганович, генерал-полковник О. И. Городовиков; чит илләр белән Культура Элемтәсе Бөтенсоюз Җәмгыяте идарәсе председателе В. С. Кеменов иштәшләр һәм Монголия Халык Республикасының СССР дагы илчесе Самбу озатып калды.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— 1941 нче елда үткәрелгән исәп буенча Һиндстанда 389 миллион кеше исәпләнә. 1931 нче елда Һиндстанда 338.119 мең кеше исәпләнә иде.

— Лондонда, хуҗалыкның төрле өлкәләрендәге фәнни-тикшерену эшләре работникларының конференциясе булды. Дәүләтнең һәм фәннең хезмәттәшлеге турында Криппс доклад сөйләде. Англиянең яшь галиме Шенбергның «Сугыш көннәрендә совет фәне» дигән доклады гаять зур кызыксыну белән тыңланды. Докладчы үзенең чыгышында, совет фәненең тизлек белән алга китүе Кызыл Армиянең уңышларына ярдәм итүче факторлардан гыйбарәт, дип аеруча күрсәтте.

— АКШ та минераль ресурсларны файдалануны координацияләү буенча бюро төзелгән.

— Канадада 1943 нче елда илдә һәм илдән тыш булган урыннарда хәрби һава көчләрен тоту өчен бер миллиард доллар акча билгеләнгән.

— Узган ел эчендә Нью-Йоркта туучыларның саны мең кешегә 15,6 дан 22 гә арткан. Шуның белән бер үк вакытта балаларның үлүе рекордлы дәрәҗәдә түбән санга төшкән.

— Сугыш башланганнан алып 1942 нче елның ахырына кадәр Американың сәүдә флоты үзенең личный составының 3,8 процентын югалткан.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген *„Хуҗа Насретдин“*. 11 нче февральдә—*„Печән өстендәге эт“*.

Зур драма театры. Бүген һәм 10, 11 нче февральдә — *„Маскарад“*.

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 10 нче февральдә — *„Башмагым“*. 12 нче февральдә—*„Евгений Онегин“*.

Татарстан дәүләт филармониясе 10 нче февральдә Менжинский исемендәге клубта А. С. Пушкинның туына 105 ел тулуга багышланган концерт. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар сатыла.

Дәүләт циркы. Бүген көндезге 1 сәгатьтә, кичке 6 һәм 9 сәгатьтә еч тамаша һәм французча көрәш ярышлары.

„Электро“ — музыкаль комедия *„Антоша Рыбкин“*.

„Унион“—*„Котовский“*.

„Пионер“ көндез һәм кич — *„Корыч ничек чыныкты“*.

„Чаткы“—*„Өч мушкетер“*.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 75—14, типография 36—60

ПФ 37 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 225